**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**БОЕРЫК**
***20.07.2017***

**БОЕРЫК**
**№ *04-14-96***

Казан ш.

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турында

"Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында" 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы 17 нче Федераль законның 1 нче маддә 3 нче пункты нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибен (алга таба - Тәртиб) расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Рәис вазифасын үтәүче *Имза* И.Г. Бәһаутдинов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ

ТЕРКӘЛДЕ
***03.08.2017***
ТЕРКӘҮ НОМЕРЫ: ***4051***

Татарстан Республикасы сатып алулар
буенча Дәүләт комитетының
_________ елның ________ номерлы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү
Тәртибе

1. Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында (алга таба - Дәүләт комитеты) бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе (алга таба - Тәртиб) “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы 17 нче Федераль законның 1 нче маддә 3 нче пункты нигезендә эшләнгән.

Бу тәртиб Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында (алга таба - гражданлык хезмәткәрләре) түләүсез нигездә иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милекчеләр ширкәте (алга таба - коммерцияле булмаган оешма) белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү процедурасын регламентлый.

Бу тәртиб Дәүләт комитетында яллаучының вәкиле Дәүләт комитеты рәисе булган Татарстан Республикасы гражданлык хезмәткәрләренә кагыла.

2. Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү турында гариза (алга таба - Гариза) гражданлык хезмәткәре тарафыннан язма формада бу Тәртипнең 1 нче Кушымтасы буенча төзелә.

3. Гражданлык хезмәткәре Гаризаны коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

4. Җаваплы зат Гаризаны алынган көнне бу Тәртипкә 2 нче Кушымта нигезендә Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карап, аның нәтиҗәләре буенча йомгак ясый.

Җаваплы зат Гаризаны алдан караган вакытта Гариза биргән гражданлык хезмәткәреннән коммерцияле булмаган оешма идарәсендә планлаштырылган катнашу буенча вазифаларын билгеләүче язма аңлатма һәм документлар соратып ала ала.

Нәтиҗә граждалык хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдимне үз эченә алырга тиеш.

6. Гариза теркәлгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча җаваплы зат Нәтиҗә һәм башка материалларны (булган очракта) Гаризага беркетеп Дәүләт комитеты рәисенә (аның вазифаларын башкаручыга) граждалык хезмәткәренә түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен тапшыра.

Дәүләт комитеты рәисе (аның вазифаларын башкаручы) Гариза алынганнан соң ике эш көне дәвамында карар кабул итә.

7. Җаваплы зат Дәүләт комитеты рәисе (аның вазифаларын башкаручысы) карар кабул иткәннән соң ике эш көне дәвамында граждалык хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа кул куйдырып, кадрлар бүлеге мөһере сугылган Дәүләт комитеты рәисе резолюциясе булган Гариза күчермәсен тапшыра. Дәүләт комитеты рәисе резолюциясе белән Гаризаның төп нөсхәсе граждалык хезмәткәренең шәхси эшенә өстәлә.

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә 1 нче кушымта

________________________________

_____________________________

(ФИО., вазифа һәм структуралы

_____________________________

бүлекчә, тору урыны адресы

_____________________________

телефон номеры)

Гариза

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү турында

Миңа идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә (кирәклесе астына сызарга) рөхсәт бирүегезне сорыйм _________________________________________________________________

(иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык,

_________________________________________________________________________

дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милекчеләр ширкәте исеме)
түләүсез нигездә ___________________________________________________________

_________________________________________________________________________

(бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган яки коллегиаль идарә органы исеме)

____________ (дата)    _________________ (имза)    ____________________________ (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренә яллаучы вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү гаризаларын теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № | Дата | Гаризаны бирүченең ФИО, вазифасы | Гариза бирүченең имзасы | Теркәүченең ФИО | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |